Республика Татарстан

СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

e-mail: sab.sab@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

“17” январь 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2014 елның 5нче мартында кабул ителгән 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алуы, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны тормышка ашырудан кергән акчаларны күчерү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2018 елның 30 октябрендәге 387-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 15.01.2019 № 02-08-02-2019 протесты нигезендә, Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе турында” 2014 ел, 5 март, 13 нче номерлы карары белән расланган нигезләмәгә, түбәндәге үзгәреш кертергә:
1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 2 абзацында «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен "даими (штат) нигездә комиссиядә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән" сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Саба шһәр җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча бастырып чыгарырга.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Р.М.Хәсәнов